СОВЕТ УРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423706, Республика Татарстан
Мензелинский район, д. Урусово, ул. Дружбы, .42

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423706, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Урыс авылы, Дружбы урамы, д.42

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге Советы

КАРАР

« 22 » август 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга һәм территорияләргә якын урыннарның чикләрен билгеләү турында» 15.04.2019 ел № 1 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 22.11.1995 № 171- ФЗ Федераль закон, «Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать тукланиуы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән янәшәдәге территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 23.12.2020 № 2220 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга һәм территорияләргә якын урыннарның чикләрен билгеләү турында» 15.04.2019 ел № 1 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта «100» санын «50» санына алмаштырырга.

2.Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Урыс авыл җирлеге башлыгы И.С.Аксюкова